**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » апрел, 2019 ел** **№ 108**

**«Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүгә яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында Нигезләмә раслау турында» 2017 елның 13 сентябрендәге 60 номерлы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатында Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы **карар** чыгарды:

1. 2017 елның 13 сентябрендәге 60 номерлы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы Карары белән расланган Арча муниципаль районы « Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүгә яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында Нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүгә яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, муниципаль хезмәткәрләр) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законының 14 маддәсе 1 бүлеге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде һәм муниципаль хезмәткәрләрнең түләүсез нигездә иҗтимагый оешмалар, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары,

торак милекчеләре ширкәтләре белән идарә итүгә (алга таба – муниципаль хезмәткәрләрнең түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуы) эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибен билгели.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы,
Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы рәисе Фәхретдинов Р.Ә.

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ